**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

20.03.2025 291-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карар кабул итү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы комиссиясе турында» 2022 елның 17 мартындагы 197-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карар кабул итү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы комиссиясе турында» 2022 елның 17 мартындагы 197-п номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 14.03.2023 ел, № 263-п, 06.06.2023 ел, № 695-п боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерыкның 4 пунктында «министр урынбасары И.И.Гобәйдуллинны» сүзләрен «министр урынбасары А.А.Тугушевны» сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән боерык белән расланган Татарстан Республикасы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү турында карарлар кабул итү комиссиясе хакындагы нигезләмәдә:

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Комиссия рәисе, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзаларыннан тора. Комиссия әгъзалары саны 12 кеше булырга тиеш.»;

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Комиссия эшен рәис – җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары җитәкли. Комиссия рәисе урынбасары булып Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсенең җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге башлыгы тора.»;

күрсәтелгән боерык белән расланган Татарстан Республикасы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар кабул итү комиссиясе составында:

комиссия составыннан Е.К.Вахитованы, С.Т.Вахитовны, А.С.Полюшковны, Э.М.Фазлыеваны чыгарырга.

Комиссия составына кертергә:

Алимов Гадел Равил улын – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының геологик күзәтчелек бүлеге башлыгын;

Заһидуллин Роберт Айвар улын – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгын;

Мөхәммәтшин Ренат Нурислам улын – Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаменты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча);

Мөхәммәтова Агнесса Эдуард кызын – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы белгечен;

Чесновока Ирина Валерьевнаны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны җайга салу бүлеге җитәкчесеб.

комиссия әгъзасы - Лукина Людмила Александровна – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге башлыгы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге башлыгы – Комиссия рәисе урынбасары;».

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары А.А.Тугушевка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков